| СОВЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«01» апрель 2019 нчы ел Мәлки авылы №3

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен вәкил яклаучы (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” гы 2017 елның 29 июлендәге 217 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 августындагы 13 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен вәкил яклаучы (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен вәкил яклаучы (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезмәләгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче пунктта “бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның, башкарылуын контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башлыгы** **Ф.П. Поляков**